| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| 422650, пгт. Рыбная Слобода, ул. Ленина, дом 48 | | 422650, Балык Бистәсе, Ленин урамы, 48 нче йорт |

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.06.2016 Балык Бистәсе штп. № 98пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 19 декабрендәге 215 пи номерлы карары белән расланган «2015-2017 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 6.1 өлеше, «Терроризмга каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы, «Экстремистлык эшчәнлегенә каршы тору турында" 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы һәм 2018 елның 26 апрелендә (№ Пр-1069) Россия Федерациясе Президенты тарафыннан расланган, Россия Федерациясендә терроризм идеологиясенә каршы торуның комплекслы планын үтәү буенча Милли террорчылыкка каршы комитет тәкъдимнәрен исәпкә алып, карар бирәм:

1.Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 19 декабрендәге 215 пи номерлы карары белән расланган «2015-2017 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау» муниципаль программасына (Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 15 апрелендәге 49пи номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

кушымтаның 4 бүлеге таблица " 2015-2017 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау" муниципаль программасының максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау» түбәндәге эчтәлекле 4.11 пунктны өстәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «4.11. Милләтара һәм төбәкара ызгышлар уятуга, шулай ук экстремистик материаллар таратуга юнәлтелгән фактларны ачыклау һәм булдырмау максатыннан Интернет-ресурсларга даими мониторинг ясауны тәэмин итәргә. | Мәгариф бүлеге, яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге, социаль-мәдәни өлкә бүлеге, Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлеге начальнигы урынбасары (Мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүмат куркынычсызлыгы буенча), РФ ЭЭМ бүлеге (килешү буенча) | 2016 – 2017 еллар» | | | | | | - | - | - |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Х.Хәбибуллин